# Мәңге яшә,
# Көшкәтбаш!

**Эшне башкаручы:** Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе «Балтач урта гомуми белем мәктәбе»нең 11-В сыйныфы укучысы **Нәбиева Алия Алмаз кызы**

**Җитәкче:** татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Закирова Руфия Әдһәм кызы**



# Эшнең максаты:

Балтач районында туризмны үстерү юнәлешендә өйрәнүләр һәм эзләнүләр алып барып, Көшкәтбаш авылы турында мәгълүматләр туплау, аның туристларны җәлеп итәрлек матурлыгы барлыгын исбатлау.







# Эшнең бурычлары:

- Туган як, авыл турындагы белемнәрне киңәйтү;
- Авылның күренекле кешеләренә хөрмәт тәрбияләү;
- Туристларны, килгән кунакларны  авыл тарихы, аның урнашу урыны белән таныштыру;
- Патриотик хисләр формалаштыру;
- “Мәңге яшә, Көшкәтбаш!” дип исемләнгән сайт төзү.





# Эшнең актуальлеге

Һәр кешегә үзенең туган телен, туган җирен, милләтен, аның тарихын, гореф-гадәтләрен белү бик мөһим. Без – үсеп килүче яшь буын – туган илебезнең, туган җиребезнең, туган телебезнең саклаучылары, аларны тирәнтен өйрәнүче шәхесләр булырга тиешбез. Ә мондый олы бурычны үтәү үзеңнең ана телеңне, гаилә һәм нәсел, туган авыл тарихын өйрәнүдән, аларны данлаган ул-кызларны, йолаларны белүдән башланып китә. Бинһая зур тарихлы, әмма бүгенге көндә кечкенә авыллар исәбендә саналучы Көшкәтбаш авылы – минем кечкенә Ватаным, нәсел җебем тоташкан төбәк. Аны яшәтү, яшәртү – минем зур хыялым.

## 2026 ел

- Россия Федерациясендә – **Халыклар бердәмлеге елы**
- Татарстан Республикасында – **Хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы**

**Көшкәтбаш авылының тарихын, бүгенгесен өйрәнеп, минем тарафтан сайтлар, экскурсияле видеоязмалар эшләнде. Алар белән тулырак QR-кодлар аша таныша аласыз.**




видео

сайт

# Чал тарихлы Көшкәтбаш авылы...

Хәзерге Көшкәтбаш авылы урнашкан урында элек марилар яшәгән. Тирә-ягын кара куе урман чолгап алган бу авылның исеме Нунинеш дип аталган. 1552-1560 елларда Арча районы Мәтәскә авылыннан бик күп татарлар шушы мари авылына килеп урнашканнар. Авылның исеме дә мари сүзеннән алынган “кушкет” барысын да алып китүче “куркыныч” мәгънәсендә, чөнки Көшкәт елгасы кисәк яуган көчле яңгырлардан соң яки язгы ташулар вакытында ярларыннан чыгып, ташып күп кенә корылмаларны агызып алып китә торган була.

тулырак

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **XVI йөзнең II яртысы** Авылга нигез салына | **1821 ел** Беренче мәчет салына | **1870 ел** Беренче мәдрәсә эшли башлый | **1923 ел** Авылда мәктәп ачыла | **1942-1943 еллар** Беренче медпункт эшли башлый | **1945 ел** Авылда клуб ачыла | **1956 ел** Балалар бакчасы эшли башлый |
| **1952-1957 еллар** Авыл радиолаштырыла, ут линияләре үткәрелә | **1973-1974 еллар** Беренче ясле-бакча ачыла | **1974-1975 еллар** Су үткәрелә, колонкалар куела | **1995 ел** Авыл тулысынча газлаштырыла | **1998 ел** Зур таш кибет бинасы кулланышка тапшырыла | **1999 ел** Авыл белән олы юлны тоташтыручы күпер салына | **2000 ел** Яңа ике катлы таш клуб бинасы ачыла |

# Көшкәтбашнын иң зур чишмәләре

## ГАЛЛӘМ БАБАЙ ЧИШМӘСЕНЕҢ ПАСПОРТЫ

- **Чишмәнең исеме:** Галләм бабай чишмәсе.
- **Урыны:** Көшкәт елгасының сул як ярындагы тау асты, авылга кергәндә сул як
- **Чыганакның барлыкка килү юрамасы:** билгеле түгел.
- **Чыганак турында тарихи мәгълүмат:** Көшкәтбаш авылының иң борыңгы чишмәсе. Бөек Ватан сугышында исән калып туган авылына кайткан ветеран Галләм бабай чишмәне чистартып торган. Татарстан хокуматенең чишмәләрне барлау турындагы карары чыккач, «Яппар» урынына «Галләм чишмәсе» исеме бирелә.
- **Суын кайсы елгага коя:** Көшкәт елгасы.
- **Әйләнә тирәсенең табигате:** тау астында, Көшкәт елгасының сул ягында урнашканга күрә, чишмә кырында таллык үзенә күрә чишмә тирәсенә матурлык өсти. Таллыктагы сандугач тавышлары чишмә тирәсен сихри ямьгә күмә.
- **Чыганакны төзекләндерү:** чишмә тирәсе рәшәткәләп алынган, чишмәнең үз өе дә бар.
- **Чишмәне пычрату чыганаклары һәм саклау чаралары:** авыл халкы һәм мәктәп укучылары тарафыннан чистартыла.
- **Чыганакны файдалану:** авыл халкы су алу һәм ял итү урыны.
- **Чыганакны төзекләндерүченең, оешманың исеме, төзекләндерү датасы:** 2016нчы елда авылдашыбыз Фазылҗанов Фаил чишмә өен төзекләндерә.




## КӨМӘШИЯР ЧИШМӘСЕНЕҢ ПАСПОРТЫ

- **Чишмәнең исеме:** Көмәшияр чишмәсе.
- **Урыны:** Көшкәтбашның көньяк-көнчыгыш өлеше.
- **Чыганакның барлыкка килү юрамасы:** Аксакаллар әйтүе буенча Көмәшияр басуында җирне бораулаганда ничәдер метр тирәнлеккә җиткәч бик көчле су фонтаны бәреп чыккан. Көчле цемент ярдәмендә генә фонтанны томалаганнар. Әлеге басу исеме белән бәйләнгән Көмәшияр чишмәсенең исеме дә!

**Чыганак турында тарихи мәгълүмат:** XX нче гасырның 60 елларында Көшкәт елгасының сазлы урынында яшь чыганак буларак барлыкка килә.

**Суын кайсы елгага коя:** Көшкәт елгасы.

**Әйләнә тирәсенең табигате:** чишмәнең өске өлешендә ылыслы агачлар үсә.

**Чыганакны төзекләндерү:** төзекләндерелмәгән.

**Чишмәне пычрату чыганаклары һәм саклау чаралары:** авыл халкы һәм мәктәп укучылары тарафыннан чистартыла

**Чыганакны файдалану:** авыл халкы су алу һәм ял итү урыны буларак файдалана.

**Чыганакны төзекләндерүченең, оешманың исеме, төзекләндерү датасы:** билгеле түгел.




## КИРӘМӘТ ЧИШМӘСЕНЕҢ ПАСПОРТЫ

- **Чишмәнең исеме:** Кирәмәт чишмәсе (5нче кушымта).
- **Урыны:** Көшкәтбашның көньяк өлешендә.
- **Чыганакның барлыкка килү юрамасы:** «Кирәмәт» сүзе билгеле бер урынның хуҗасы булып исәпләнгән, табынила торган илахи көч, рух дигәнне аңлата. Авыл аксакаллары фикеренчә, элек бу авылда мари халкы торганлыктан, аларның табыну урыны булган дигән риваять бар.
- **Чыганак турында тарихи мәгълүмат:** билгеле түгел.
- **Суын кайсы елгага коя:** Көшкәт елгасы.
- **Әйләнә тирәсенең табигате:** Көшкәтбаш авылын әйләндереп алынган тау битенең аскы өлешендә чыга.
- **Чыганакны төзекләндерү:** төзекләндерелмәгән.
- **Чишмәне пычрату чыганаклары һәм саклау чаралары:** авыл халкы һәм мәктәп укучылары тарафыннан чистартыла.
- **Чыганакны файдалану:** авыл халкы су алу һәм ял итү урыны буларак файдалана.
- **Чыганакны төзекләндерүченең, оешманың исеме, төзекләндерү датасы:** билгеле түгел.




## АКНАРАТ ЧИШМӘСЕНЕҢ ПАСПОРТЫ

- **Чишмәнең исеме:** Акнарат чишмәсе
- **Урыны:** Көшкәтбашның көнбатыш өлешендә.
- **Чыганакның барлыкка килү юрамасы:** билгеле түгел; элек бу тирәдә куе урман булган, исеме дә шуннан чыгып, Акнарат дип атала.
- **Чыганак турында тарихи мәгълүмат:** XIX нче гасырның ахырында барлыкка килгән дигән фараз бар.

**Суын кайсы елгага коя:** Өтәр елгасы.

**Әйләнә тирәсенең табигате:** Кызыл китапка кертелгән алтын түй чәчәген, наратбашны, каз суганы (гусиный лук) очратып була. Җәй көне суы салкын, кышын җылы була. Өтәр инеше t -15 градустан түбән булганда гына боз белән каплана.

**Чыганакны төзекләндерү:** Чишмә тирәсе рәшәткәләп алынган, һәм чишмәнең үз өе дә бар.

**Чишмәне пычрату чыганаклары һәм саклау чаралары:** Өтәр елгасы көтүлек җирләре буларак файдаланыла, инеш мал-туар йөрү сәбәпле бик нык пычрана, авыл халкы һәм мәктәп укучылары тарафыннан чистартыла.

**Чыганакны файдалану:** 30 м читтә, басуга су җыю башнясы утыртылган, чишмә суы башнядан өйдәге краннарга килә.




видео

сайт

Көшкәтбаш чишмәләре турында күбрәк беләсегез килсә, Сезне **«Чишмә – Җир-Ананың сокландырлык могҗизасы»** дип аталган сайтымда көтеп калам!





# Авылын данлаган ул-кызлар



**Ильяс Шаһиев**
Журналист,
телевидениедә
алып баручы

**Сәйдәш Нурмиев**
Татарстан Республика-
сының атказанган
укытучысы



**Гөлназ Әхмәдиева**
Шагыйрә, журналист





**Фоадия Сәлимҗанова**
Чаңгычы, спорт остасы

**тулырак**

# Авылын данлаган ул-кызлар

**Әлфия Габдуллина**

Язучы




**Зөһрә Рамазанова**

Шагыйрә




**Лилия Гарифуллина**

Мөгаллимә, шагыйрә




**тулырак**

# Көшкәтбаш осталары –
# Фазылҗанов Фаил Гайнан улы белән
# Сафин Фаяз Фарис улының шедеврлары




тулырак

Көшкәтбаш авылы – зур тарихлы авыл. Аның киләчәге дә бик матур булсын иде дип телим.
Бер як нәсел җебем шушы авылга тоташканга мин бик шатмын. Үземне Көшкәтбашның бер баласы итеп тоям.
Авылга кайткан саен шуны тоеп сокланам: табигате генә түгел, кешеләре дә бик бердәм, кешелекле аның!
Авылыбыз истәлекле урыннарга, төзек, матур йортларга, иҗат әһелләренә бай булуы белән дан тота.
Әмма бүгенге көндә күңелне борчып торган проблемалар да юк түгел. Эш урыннарының бик аз булуы
яшьләрне авылдан читкә җибәрә. Авыл бетмәсен иде, гөрләсен иде! Киләчәктә аның тагын да
җанланып китүен күреп куанырга язсын иде! Көшкәтбаш авылын өйрәнгән әлеге хезмәтем
авылның яңа сулыш алып, яшәреп китүенә бер адым булыр дип ышанабыз.
Югалтасы килми бу газиз төбәкне, гүзәл авылны!

# Мәңге яшә,
# Көшкәтбаш!

